СОВЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с.Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕЖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)53-2-36, факс (84366)53-2-36. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

# СЕҖЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
# КАРАРЫ

«14» декабрь 2023 ел № 106

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында Сеҗе авыл җирлеге Советының 2022 елның 25 февралендәге 49 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроле турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнарга ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Сеҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына таянып, Сеҗе авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында Сеҗе авыл җирлеге Советының 2022 елның 25 февралендәге 49 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге» 3 нче кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http:arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы Р.В.Хамидуллин

СОВЕТ СИЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Сеже авыл җирлеге Советының
14 декабрь 2023 ел, №106
карарына кушымта

«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеже авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге

1. Җирле үзидарә органына реклама тактасын килештерү турында гариза җибәрү факты булмаганда, автомобиль транспортын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәт күрсәтү буенча контрольдә тотылучы затның эшчәнлек башлаган көненнән алып 90 календарь көн узу.

2. Кварталда, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, шул ук вакыт аралыгында әлеге эшләрне башкару өчен билгеләнгән җыештыру һәм махсус техника санының кимемәве белән, объектларны һәм төзекләндерү элементларын җыештыру буенча эшләрне башкару бурычы йөкләнгән оешма хезмәткәрләре санының 50 һәм аннан да күбрәк процентка кимүе.

3. Ике календарь атна дәвамында, аннан алдагы чор белән чагыштырганда, хезмәт күрсәтү территориясендә объектларны һәм төзекләндерү элементларын җыештыру буенча эшләрне башкаруны үз бурычларына керткән оешманың хезмәт күрсәтү территориясендә травматология ярдәме сорап мөрәҗәгать иткән җәрәхәтләнү алган гражданнар санының 15 һәм аннан да күбрәк процентка артуы.

4. Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) килү ихтималы турында сөйли торган дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре һәм гражданнардан, оешмалардан алынган һәм (яки) килгән мәгълүматларның дөреслеген бәяләүгә юнәлдерелгән чаралар нәтиҗәсендә аңа карата таләпләр муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән, төзекләндерү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре булган контроль объектының торышыннан тайпылуның 30 календарь көн эчендә өч һәм аннан да күбрәк очрагы ачыклану турында мәгълүмат булу.

5. Контрольдә тотылучы затка карата төзекләндерү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозган өчен административ хокук бозу турындагы эш буенча административ җәза билгеләү турында бер ел эчендә кимендә биш карар булу.

6. Ике календарь атна дәвамында, аннан алдагы чор белән чагыштырганда, торак пунктның бер административ-территориаль берәмлеге (урам, микрорайон) территориясендә җәрәхәтләнү алуга бәйле рәвештә травматология ярдәме күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткән гражданнар санының 15 һәм аннан да күбрәк процентка артуы.